Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның 20 ноябрендәге № 176

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының "Торак пунктлар чикләре турында мәгълүмат белән тулыландыру өлешендә авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан пунктларга карата генераль план әзерләү кирәк түгеллеге турында ,«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 16.12.2013 ел, № 213 карарына үзгәрешләр кертү хакында (редакциядә 07.09.2020 ел, №280, 28.02.2022 ел, №91, 31.10.2022 ел, №116)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан килештерелгән 2023елның 19 октябрендәге елгы уңай нәтиҗә нигезендә № 10-53/12945 Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына (электрон адрес буенча урнаштырылган кушымталарга һәм проектларга туры китереп) ttps://kamskoye-ustye.tatarstan.ru/shema-territorialnogo-planirovaniya-kamsko.htm), Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2013 елның 16 декабрендәге 280 номерлы карары (2020 елның 07 сентябрендәге 280 номерлы, 28.02.2022 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына түбәндәге торак пунктларның чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Варварино авылы;

1.2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Осинники п..;

1.3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Шәпкә авылы.

2. Әлеге карарны Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык, ТКХ һәм төзелеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
район Советы рәисе Н. А. Вазыйхов